РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» апрель 2024 ел Олы Кайбыч ав. №263

Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 657-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 17 июнендәге 170 номерлы карары белән (05.08.2020 № 246, 18.10.2021, № 65, 01.12.2023 №229 үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт тарафыннан теркәү уздыру өчен юлларга.
3. Әлеге карарны «Кайбыч таңнары» («Кайбицкие зори» ) район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Рәис А.И.Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2024г "26" 04
263 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр

1. 6 статьяның 1 өлешендәге 34 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34) Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү;».

2. 45 статьяның 1 өлешендәге 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә, су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне дә кертеп, билгеләү, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләрен билгели;».